Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

«15» сентябрь, 2022 ел № 15

«Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү комиссиясе составын раслау турында» 2022 елның 20 июлендәге 10 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясы, «Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү өчен формалаша торган килештерү комиссиясе турында» 2015 елның 20 мартындагы 177 номерлыТатарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, «Комплекслы кадастр эшләрен оештыру турында» 2020 елның 31 мартындагы 237 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең 2022 елның 29 августындагы 14-22@/23478-э номерлы хаты нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү комиссиясе составын раслау турында» 2022 елның 20 июлендәге 10 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертергә:

1.1 әлеге карарның 1 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http:// www.pestreci.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керүен билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Колай авыл җирлеге башлыгы Поповская Н.В.Поповская

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КУЛАЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУЛАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1633605800

Кушымта № 1
Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башкарма комитеты карарына
15 сентябрь, 2022 ел № 15

2022 елда Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге территориясендә комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашуын килештерү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Н.В.Поповская | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары | |
| Дәүләтханов И.Р. | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе |
| Шәйхетдинов Р.Р. | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Беляков М.В. | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы |
| Рогожкин М.А. | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары |
| Фәсхетдинов Р.Р. | Татарстан Республикасында һәм Ульяновск өлкәсендә дәүләт милке белән идарә итү буенча Федераль агентлыкның төбәкара территориаль идарәсе җитәкчесе урынбасары |
| Тиханова Э.А. | Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенең Питрәч һәм Балык Бистәсе районнары буенча муниципальара бүлек башлыгы |
| Хәбибрахманов Р.Р. | «ТР БТИ» АҖ техник директоры |
| Евстафеев Н. И. | «Энтузиаст» коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте рәисе |
| | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы (килештерү буенча) |